Чыганак: Макаров, Марс. Сәнгатебез йолдызлары: публицистик мәкаләләр, истәлекләр / М. А. Макаров. – Казан: Татар. кит. нәшр. , 2011. – 111 б.

## *Татарның чын моңсары иде*



Яшерен-батырын түгел, Александр Ключарев белән якыннан танышу теләге миндә аеруча зур иде. Ниһаять, күпмедер вакыттан соң теләгем кабул булды.

Казан музыка училищесын тәмамлаганнан соң, курсташ дустым Нәсыйх Вилданов белән Татар җыр һәм бию ансамбленә баянчы булып эшкә урнаштык. Шунда ук «Тула өмәсе» дигән музыкаль-хореографик композиция әзерләү эшенә чумдык, чөнки әзерлек өчен билгеләнгән вакыт бик аз калган иде. Безгә тиздән Башкортстан Республикасына һәм Себер шәһәрләренә гастрольләргә чыгарга кирәк. Композициягә музыканы Александр Ключарев бик ашыгыч рәвештә язып, эшен тәмамлап килә иде бугай.

Репетиция вакытында без, баянчылар, бик бирелеп биючеләргә уйнап утырган вакытта, залга уртача буйлы, мөлаем йөзле, ап-ак чәчле бер карт килеп керде. Минем янда утырган Нәсыйх, баян тавышын басып, «Ключарев килде!» дип әйтүгә, барыбыз да, алдан сөйләшкән кебек, уйнаудан туктап калдык. Хөрмәт йөзеннән, күрәсең, балет җитәкчеләре, биюче артистлар – бөтенесе дә игътибарларын чал чәчле Ключаревка юнәлттеләр.

Беренче карашка ук ул безгә бик ягымлы булып күренде. Йөзе җитди, күз карашы моңсу, йөреше салмак, килеш-килбәтенә караганда үзеннән өлкәнрәк күренгән кебек.

Ключарев, бию залына кергәч, иң элек барыбызга да тыйнак кына баш иде. Кулындагы нота-кульязмаларын фортепьянога куеп маташкан арада, күңелдә Ключаревның бер инструменталь темасы чыңлап узды. Шушы икән Ключарев дигәннәре дип уйлап куйдым мин. Ул ансамбльнең художество җитәкчесе Җәүдәт Айдаров белән бераз сөйләшеп алды да, салмак адымнар белән туп-туры безнең янга килеп, барыбыз белән дә кул биреп күрешеп чыкты. Аннары:

– Ну с такими «собаками» дело пойдет! – дигән шаян сүз дә әйтеп куйды. («Собака» – Ключаревның мактау сүзе икән.)

Минем янда баян тотып утырган Нәсыйх пырхылдап көлеп җибәрде. Атаклы композитор алдында каушавым бераз кими төшсә дә, мин әле һаман да тере Ключаревны күрүдән сихерләнгәнмен. Көләргә кыймыйча газапланып утырам шулай.

– Ну, теперь квартетом дадим жару! – дип, Ключарев безгә баян өчен язылган партияләрен өләшә башлады.

Без аны беренче очрашуда ук үз иттек. Дулкынлану, каушау кебек халәт юкка чыкты. Шул көннән башлап Александр Сергеевич һәр көнне диярлек ансамбльгә килеп йөри башлады. Ул эшне ашыкмыйча, салмак кына башкара, ләкин куелган максатына бик тиз ирешә торган кеше иде.

Ключарев «Тула өмәсе» композициясен бер ай эчендә диярлек тәмамлап бетерде. Башкаручы артистлардан һәм җитәкчеләрдән музыкага карата бер генә каршылык та булма-

ды. Һәрбер номер милли колорит белән бизәлгән. Хор тавышлары өчен язылган партияләр дә бик көйле, аңлаешлы һәм халыкчан. Аның музыкасы хакында фикер алышулар, гадәттә, «Ключарев язса яза инде» дигән сүзләр белән тәмамлана. Бигрәк тә бию өчен язылган көйләре «аяктан егарлык» була торган иде. «Музыка үзе очындырып биетеп тора, сезгә көчәнәсе дә юк», – дип әйтә торган иде балет төркеме җитәкчесе Мансур Гатиятуллин үзенең биючеләренә. Әйе, биюгә килгәндә, дәрт һәм моң буенча Ключарев үз стилендә, үз стихиясендә иде шул.

Башкорт бию ансамбленең бер биюче артисты үзләренең танылган баянчы-композиторы Әлфәрит Солтановка:

– Менә син радио аша һаман Ключаревның бию көйләрен башкарасың, ә нишләп соң үзең шундый ук биюләрне язмыйсың? – дигән.

Ә теге аңа:

– Кая инде безгә андый башкорт биюен чыгарырга, без бит Ключарев түгел, – дип җавап биргән.

Шул җәһәттән мондый галәмәтләр искә төшә. Баштарак без, татар баянчылары, «Шук кыз» дигән башкорт стилендә язылган тылсымлы бию көен ничә еллар буена башкорт халык биюе дип санап, сәхнәләрдә башкарып йөреп, аның Ключарев музыкасы икәнен белмәгәнбез икән. Уфа белән Казан арасында булган мәдәни дуслык та Ключарев иҗаты белән бәйләнгән. Фәйзи Гаскәров җитәкләгән Башкорт бию ансамбленең озак еллар буена Ключарев музыкасына таянуын исәпкә алсак, бу танылган ансамбльнең ярты уңышы шул мәшһүр композитор иҗатыннан яралгандыр дип уйларга була. Рус милләтеннән була торып та, язмышны татар-башкорт музыкасы белән бәйләү уен эш түгелдер. Үзе тыйнак булганга, безнең тыйнак халыкка күңеле ят-



кандыр аның, мөгаен. Бу бик серле һәм тормышта сирәк була торган хәл дип саныйм мин. Ул гомерен тулысынча халык иҗаты белән бәйләде, халык фольклорының бөтен нечкәлеген өйрәнде һәм музыкаль әсәрләрендә бик уңышлы файдалана белде.

Ключарев – халык музыкасы фольклорын җыючыларның атасы дисәм, музыка белгечләре минем фикерем белән килешер дип уйлыйм. Бигрәк тә милли бизәкләрдә зур белгеч иде композитор. Аның хәтта моң-бормаларда үзен гаҗәеп оста итеп таныткан Илһам Шакировка да кайбер очракларда татар бормаларына кагылышлы киңәшләр бирүе турында сөйлиләр иде.

Әлфия Авзалова яшь вакытында башкарган, әлегә чаклы радиоязмаларда без тыңлый торган Солтан Габәшинең милли бормалар белән бизәлгән «Кәккүк» җырының хор һәм аккомпонемент партияләренең дә Ключарев эшләнешендә икәнен күбесе белмидер әле. Чөнки күп очракта, радиоэфирда бу күркәм җыр яңгыраганда, көй авторын гына искә алалар. Ә бит бу җырның уңышы Ключарев бизәлешендә алтын фондыбызга керүгә иреште дисәк, бер дә артык булмас.

А.Ключарев турында зур бер роман язып булыр иде. Кайбер күренекле сәнгать ияләре шәхес буларак күңелдә озак яшәмиләр, алардан истәлек-мирас булып әсәрләре генә кала. Сәнгать әһелләре турында азмы-күпме гайбәт сатулар булгаламый тормый, андый вакытларда безнең халык еш кына болай ди: «Бар да Ключарев була алмый шул».

Александр Сергеевич иҗат кешесен һәрвакыт яклый иде, дөреслек, гаделлек өчен ул мөмкин кадәр көрәште, тырышты. Үз вакытында Татарстан Композиторлар берлеге халыкчан җырлар язучы үзешчән авторларга каршылык күрсәтә иде. Радионың сәнгать шурасы утырышларында А.Ключарев, әгъза

буларак, үзенең туры сүзе белән күп кенә авторларның җырларын коткарып калды. Без баянчыларның эшкәртмәләрен матбугатта бастыру өчен Берлекнең рөхсәт кәгазе сорала иде, алар рөхсәт бирмәгән очракта, без Александр Сергеевичка килеп сыена идек. Чал чәчле, абруйлы аксакалның сүзе күп вакыт үтемле була торган иде. Аның йомшак кына әйтелгән сүзенә каршы килергә күпләрнең кыюлыгы җитми иде, күрәсең. «Халыкка ризыкны без үзебез сайлап бирергә тиешлебез, – дия иде ул, – чөнки аның сыйфатсыз ризыкка да күнегеп китүе бик мөмкин. Халык артыннан өстерәлеп бармаска, азрак алданрак барырга кирәк».

Александр Сергеевич Ключаревның безнең арадан китүенә кырык елга якын гомер узды. Ә күңелне һаман да бер нәрсә тырнап тора. Нинди пошмас булган икәнбез без ул чакта. Күпме аралашып та, истәлеккә бергә сурәткә дә төшә алмаганбыз. Шуның өчен үземне һич кичерә алмыйм. Үзешчән композиторлар түгәрәгендә катнашып йөргән минем бер танышым аксакал белән бергә фотога төшү бәхетенә ирешкән икән. Очрашкан саен, шушы фоторәсемне карап, татлы хатирәләргә чумабыз.

А.Ключаревның югары профессиональлегә минем өчен үрнәк кенә булып калмыйча, иҗат юлымда уңай тайпылыш ясарга ярдәм итте. Аның белән якыннан танышканчыга кадәр, мин үзем турында баянчы булудан артык китә алмам дигән фикердә яши идем. Әмма шикләнүем юкка булган икән. «Каз канаты» көенә фантазияне тыңлагач, А.Ключарев аңа: «Баян өчен симфония бу», – дигән бәя бирде.

Шуннан соң миндә әллә чыннан да симфоник оркестрга берәр нәрсә әмәлләп карарга мы дигән уй туды. Очрашуларның берсендә исә ул, симфоник партитураларны өйрәнеп чыгарга киңәш итеп: «Оркестр өчен язарга



теләгән яшь композиторга Римский-Корсаковның бер «Шәһрезадә» симфониясен өйрәнү дә җитә. Бөтен консерватория белеме шунда теркәлгән», – дигән иде. Бу юлы мин «Татарстан таңнары» дигән җырымны баянга да, фортепьянога да түгел, ә оркестр һәм хор өчен язарга ният кылдым. Ул «Иң яхшы җырлар» конкурсында бүләк алды, тиздән аны радиога да яздылар. Шулай итеп, мин атаклы композитор ярдәмендә яңа юлга – профессиональлеккә омтылыш ясадым. Александр Сергеевич минем күңелемә иң якын укытучым һәм киңәшчем булып кереп калды. Консерваториянең композиция классына кабул ителмәгәч, мин, аның киңәшләрен искә төшереп, үземне юата торган идем. Ключарев дөньядан киткәч, талантлы яшь композитор Александр Миргородский аңа багышлап симфония язды. Ялгышмасам, ул әсәр, 80 нче еллар башында консерваториянең актлар залында башкарылып, бик зур бәя алган иде. Симфониянең авторы үзе дә дөнья белән бик вакытсыз хушлашты. Шунысы кызганыч: әлеге көчле әсәрне Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры читләтеп узды.

Кайчак Ключарев музыкасын, телевизордан булмаса да, радио аша ишетергә туры килгәли. Минем әни шул вакыт, күз яшьләрен сөртә-сөртә:

– И Ходаем, үзе үлеп ята, музыкасы әле дә тере, көе дә бүген чыгарган кебек! – дия иде исән чагында.

Мин дә, әни фатирына килгән саен, аның түр башында торган әллә кайчангы пианиносын күреп, совет заманнарында Александр Сергеевич белән бергә чәй эчкән чакларны сагынам. Шундый чакларда Мөхәммәт Мәһдиевнең хисле һәм моңсу сүзләре искә килеп төшә: «Кеше китә – җыры кала...»

*1996*